КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 март г.Казань № 159

«2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында

Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгын Программаның дәүләт заказчысы – яраштыручысы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда Программа чараларын тормышка ашыру өчен, бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга җибәрелә торган финанс чаралары чикләрендә акча күздә тотарга.

4. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин